**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**19.07.2021** **№ 614**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының вәкиллекле органнарына депутатлар сайлауларны финанслау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең бюджет счетын ачу турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 7 пункты, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2020 елның 23 июнендәге 103/797 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2021 елның 12 июлендәге 143/1260 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасында Җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләү һәм уздыру өчен муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләренә, башка сайлау комиссияләренә, референдум комиссияләренә җирле бюджеттан бүлеп бирелгән акчаларның счетларын ачу һәм алып бару, исәпкә алу, хисаплылык һәм аларны күчерү тәртибе турындагы инструкция нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе белән килештереп, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Сбербанк России» ГАҖ 8610/0077 номерлы өстәмә офисында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының вәкиллекле органнарына депутатларны билгеләнгән сайлауларны финанслау өчен «Җирле бюджетлардан бүлеп бирелгән акчалар» [redacted] номерлы баланс счетында бюджет счетын ачарга.
2. Күрсәтелгән счетның гамәлдә булу срогын 2021 елның 09 октябренә кадәр билгеләргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин